Лельвиж авыл җирлеге Советы

КАРАР

«16» декабрь, 2025 ел №11

Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 25 ноябрендәге 994 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Лельвиж авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 июнендәге 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлегенең вәкаләтләрне даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) (Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 7 ноябрендәге 28 номерлы, 2020 елның 21 декабрендәге 14 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 38 номерлы, 2024 елның 11 июнендәге 16 номерлы, 2024 елның 13 августындагы 26 номерлы, 2024 елның 03 декабрендәге 35 номерлы, 2025 елның 16 июньдагы 21 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 2 бүлекнең 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Муниципаль берәмлек башлыгына айлык акчалата түләү

түбәндәгедән артмаган күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфаның исеме | Айлык акчалата түләүнең күләме (сумнарда) |
|---|---|
| | Уникенче төркем (халык саны 1,5 мең кешегә кадәр) |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 23 201,0 |

б) 3.1 пунктның беренче абзацында «15 389» санын «16 928» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Лельвиж авыл җирлеге башлыгы Э.Ю.Игнатьева